СОВЕТ ПЕЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.12.2015 с. Печищи 4-29

Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең 2016 елга бюджеты турында

Статья 1

2016 елга Печищи авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын (алга таба - Җирлек ) расларга:

1) 2072,6 мең сум күләмендә Җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләме;

2) 2072,6 мең сум күләмендә Җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләме.

3) бюджетка кытлыкның иң чик күләме 0 мең сум күләмендә.

2. Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2015 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

Статья 2

1. Җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның өске чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләргә.

2. Җирлек муниципаль бурычының чикле күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

- 2016 елда - 0 мең сум күләмендә;

Статья 3

Җирлек бюджетында 2016 елга керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

Югары Ослан муниципаль районы бюджеты һәм 2016 елга Җирлек бюджеты арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 5

2016 елда Җирлек бюджетына муниципаль унитар предприятиеләрнең салымнарны түләгәннән соң калган һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләгәннән соң

калган өлеше 2015елда алынган чиста табышның 20 проценты күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

Статья 6

1. Әлеге Kaparга 4 нче кушымта нигезендә бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген расларга.

2. Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 7

1. Җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2016 елга әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

2. Чыгымнарның ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:

- 2016 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

Статья 8

Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алынучы бюджетара трансфертларны Җирлек бюджетында исәпкә алырга:

- 2015 елда әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә 1180,60 сум күләмендә.

Статья 9

Җирлекнең муниципаль хакимияте органнары 2016нче елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 10

2016 елда Җирлек милкендә булган һәм бюджет мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләренә, шулай ук архив учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр Җирлек бюджеты керемнәре составына кертелә һәм әлеге карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәүгә файдаланыла дип билгеләргә.

Статья 11

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тоткын килешүләр нигезендә Җирлек бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

Статья 12

Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Статья 13

Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы                    А.С. Шамсутдинов